**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Исполнительный комитет**
**Сухояшского сельского поселения**
**Азнакаевского муниципального района**

ул. Школьная, д. 4-2, село Большой Сухояш,
Азнакаевского муниципального района, 423325
Тел. (факс) 34-6-16
ИНН 1643009001 / КПП 164301001

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай муниципаль районы**
**Сукаеш авыл җирлеге**
**башкарма комитеты**

Мәктәп урамы, 4-2, Сукаеш авылы
Азнакай муниципаль районы, 423325
Тел. (факс) 34-6-16
ИНН 1643009001 / КПП 164301001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«19» сентябрь 2019 ел № 13

Референдум үткәрү инициативасы турында

12.06.2002 ел № 67-ФЗ «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 15 статьясы, 06.10.2003 ел №131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 22, 56 статьялары, 24.03.2004 ел №23-ТРЗ «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 17 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Сукаеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә, карар чыгарам:

1. Түбәндәге сорау буенча җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:

«Сез 2020 елда Сукаеш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, 1 төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 300,00 сум күләмендә үзара салым кертү, 2 төркем инвалидлардан бер тапкыр түләтүне киметеп, 150,00 (50%) сум итеп билгеләргә һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Зур Сукаеш авылында юлларны кардан чистарту;
- Зур Сукаеш Банки-Сукаеш, Түбән Сукаеш, Курай Елга авылларында җәй көне территорияне чабу;
- Зур Сукаеш авылында Яшьләр урамында, Мәктәп урамында, Бакчалы урамында щебенка түшәмәле юлларның чокырларын ремонтлау (сатып алу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
- Бэйрэм чараларын оештыру һәм уздыру өчен бүләкләр алу;
- Банки-Сукаеш авылында һәлак булган сугышчылар һәйкәлләрен ремонтлау (коймалар урнаштыру, буяу, агарту, эшләр өчен килешү буенча түләү);
- Түбән Сукаеш авылы зиратында коры агачларны, куакларны кисү;
- Курай Елга авылында "Дулкын чишмәсен" төзекләндерү (күперен, беседкасын ремонтлау)

ӘЙЕ ЮК».

2. Әлеге карар түбәндәге чаралар аша халыкка игълан ителергә тиеш:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Зур Сукаеш авылы, Совет ур., 30 йорт адресы буенча урнашкан, Банки-Сукаеш авылында Үзәк ур., 56А йорт адресы буенча урнашкан; Түбән Сукаеш, Кызыл юл ур., 32 йорт адресы буенча урнашкан; Курай Елга авылында, Курай елга ур., № 22 и № 23 йортлар арасында урнашкан; Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында;
- Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru,
- Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

Башлык: Закирова З.Җ.